СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ИСКЕ ИШТИРӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 14 марты № 9/40/4-2023

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 16 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«әгәр мондый килешү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү.»;

19 статьяның 2 өлешендә «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп ур., 15; Бәкер авылы, Нагорная ур., 38; Ялтау авылы, Тынычлык ур., 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.https://pravo.tatarstan.ru/

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.А.Вәлиәхмәтов